**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Мәлбагыш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Мәлбагыш авылы №58 25.08.2017

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен махсус бүлеп бирелгән урыннар һәм биналар турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 5.3 өлеше нигезендә

Мәлбагыш авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Мәлбагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге (алга таба - Мәлбагыш авыл җирлеге) территориясендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен махсус бирелгән урыннар исемлеген билгеләргә (1 нче кушымта).
2. Мәлбагыш авыл җирлегендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен урыннар исемлеген билгеләргә (2 нче кушымта).
3. Мәлбагыш авыл җирлегендә депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен урыннар бирү тәртибен расларга (3 нче кушымта).
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Азнакай муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://aznakayevo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис И.А.Әхтәмова